КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 23 апрель г.Казань № 261

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 7 март, 202 нче; 2022 ел, 17 март, 244 нче; 2022 ел, 29 апрель, 402 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1196 нчы; 2023 ел, 6 март, 214 нче; 2023 ел, 21 март, 306 нчы; 2023 ел, 17 июль, 851 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1284 нче; 2023 ел, 30 ноябрь, 1536 нчы; 2024 ел, 18 март, 155 нче; 2024 ел, 14 июнь, 427 нче; 2024 ел, 15 ноябрь, 1011 нче; 2024 ел, 10 декабрь, 1127 нче; 2025 ел, 7 март, 138 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 3 485,3 мең сумлык айлык фонды белән 174 берәмлек итеп билгеләргә, шулардан:

40 берәмлек – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 974,6 мең сумлык айлык фонды белән үзәк аппарат хезмәткәрләре, шул исәптән:

федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 361,5 мең сумлык айлык фонды белән 18 берәмлек;

Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 613,1 мең сумлык айлык фонды белән 22 берәмлек;

134 берәмлек – вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 2 510,7 мең сумлык айлык фонды белән территориаль бүлекчәләр хезмәткәрләре, шул исәптән:

федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 417,8 мең сумлык айлык фонды белән 18 берәмлек;

Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 2 092,9 мең сумлык айлык фонды белән 116 берәмлек.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин